ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 17 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая,
дом 17. Тел.(885552) 3-44-45.
E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«20 » апрель 2020 ел** **№ 8**

**«Җир салымы турында» 20.11. 2014 ел 18 номерлы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Югары Яхшый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 20.11. 2014 елның 18 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 1,5% мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләре сәнгате объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата, милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы шундый объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Югары Яхшый авылы, Үзәк урамы, 27а нче йорт, Табанлы Күл авылы, Гагарин урамы, 55 нче йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Ж. Г. Зиннатуллина